ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 039 от «25» 02 2021 г.

Муниципаль район башлыгының 2017 елның 12 сентябрендәге 095 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе каршындагы мәгълүмати-пропаганда төркеме төзү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнарының «Терроризмга каршы тору турында» 2016 елның 6 июлендәге 35-ФЗ номерлы Федераль законның 5.2 статьясында, «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 11-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, терроризм һәм экстремизм идеологиясенә каршы торуга, халыкның хокукый һәм дини грамоталылыгын арттыруга, экстремистлык характерындагы публикацияләр барлыкка килүне булдырмауга, терроризмга каршы куркынычсызлык турында халыкка мәгълүмат бирүгә юнәлдерелгән чараларны үтәү максатларында к а р а р б и р ә м:

1. Муниципаль район башлыгының 2017 елның 12 сентябрендәге 095 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе каршындагы мәгълүмати-пропаганда төркеме төзү турындагы нигезләмәгә (алга таба –Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

16. Эш нәтиҗәләре буенча төркем Мамадыш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясенә квартал саен эш нәтиҗәләре буенча хәбәр итә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район башлыгы ярдәмчесе, муниципаль районның террорчылыкка каршы комиссиясе секретаре О. Ю. Рыловка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы А.П. Иванов

000049